ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Баулы шәһәре № 238

«Россия Федерациясе Кораллы
Көчләренә мобилизация буенча
хәрби хезмәткә чакырылган хәрби
хезмәткәрләрнең гаиләләренә
социаль ярдәм һәм социаль
булышлык чаралары турында»
Баулы муниципаль районы башкарма
комитетының 2022 елның 20
октябрендәге 216 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарына ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә социаль ярдәм һәм социаль булышлык чаралары турында» Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 20 октябрендәге 216 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Махсус хәрби операциядә катнашучы мобилизацияләү буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган гражданнар, хәрбиләр һәм Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар категорияләренең гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), түбәндәге өстәмә ярдәм чаралары билгеләргә:»;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариат белешмәсе нигезендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән өстәмә ярдәм чараларын мобилизацияләү буенча Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган гражданнар, хәрбиләр һәм Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), шулай ук махсус

хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар категорияләренең гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) күрсәтергә;».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров